*Мәктәп туры*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
**ТАТАР ӘДӘБИЯТЫННАН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ**
(2024-2025 нче уку елы)
**11 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 45**

**1. Бәет жанры турында исегезгә төшерегез. Аның үзенчәлекләрен барлап языгыз. Мисаллар китерегез. (6 балл)**

**2. Фоторәсемгә игътибар итегез. Ул кайсы әсәр буенча ясалган? Әсәрнең исемен, авторын языгыз, әсәр геройларын атагыз. (6 балл)**



**3. Торгынлык чоры әдәбияты кайсы чорны үз эченә ала? Дөрес җавапны билгеләгез. (2 балл)**

а) XV – XVI гасырлар

ә) XVI гасырның икенче яртысы – XVIII гасыр

б) XIX гасыр

**4. Алтын Урда чоры шагыйрен билгеләгез. (2 балл)**

а) Сәйф Сараи

ә) Габделҗәббар Кандалый

б) Муса Акъегетзадә

**5. Әсәрләрнең авторын, жанрын языгыз. (6 балл)**

а) «И күңел...» ______________________ ____________________

ә) «Яшь йөрәкләр» _______________________ ___________________

б) «Мәхәббәт тәүбәсе» _______________________ ____________________

**6. Портретка игътибар итегез. Биредә кем сурәтләнгән? Бу әдип турында өч фактны искә төшереп языгыз. (8 балл)**



1) ____________________________

2) ____________________________

3) ____________________________

**7. Әсәрнең исемен, авторын языгыз. Әсәрне тулысы белән искә төшереп, анда бирелгән хис-кичерешләрне билгеләгез. (5 балл)**

Файдасыз бер ит кисәгеннән гыйбарәттер йөрәк, —
Парә-парә кисмәсә гыйшык-мәхәббәт кайчысы.

Тешләренең гәүһәреннән кабызып алдым менә
Мин бу шигъре, — әйтсәңез лә, энҗедән ким кай төше?

Бу татар шагыйрьләрен мөмкиндер артка калдыру,
Алга сөрсен гашыйкый анчак мәхәббәт камчысы.

Һич хуҗалыкны кабул итмәм бөтен дөньяга мин,
Булмага мөмкин икән гыйшык, мәхәббәт ялчысы.

Әмма ләззәтле дә соң яшьрен газап, яшьрен яну! —
Бар микән, белмим, моның миннән бүтән аңлаучысы?

Барча әхраре мәхәббәт миннән уңда, зан итәм, —
Кайда Фәрһад берлә Мәҗнүн! — мин аларның таңчысы!

**8. Мәхәббәт – ул... Әлеге фикерне дәвам итеп языгыз, әдәбияттан мисаллар китерергә дә онытмагыз. (10 балл)**